КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 10 декабрь г.Казань № 1125

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2023 ел, 25 декабрь, 1682 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2023 ел, 25 декабрь, 1682 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 16 апрель, 256 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә, 26 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«гражданны (гаилә әгъзасын) «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакыру;

махсус хәрби операциядә катнашу өчен граждан (гаилә әгъзасы) белән «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы

53-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясы нигезендә хәрби хезмәт үтү турында контракт, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль законның 22[1] статьясы нигезендә ирекле формированиедә булу турында контракт төзү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин